**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“27” ноябрь 2022ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яштән өлкәнрәк гражданнардан,1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- материаллар сатып алу, Төрекләр авылы зиратына койма кору (килешү буенча эшләр өчен түләү).
- территорияне чистарту үлән чабу, агач кису (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- урам яктырту (лампаларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) лампалар сатып алу;
- Төрекләр авылында (Киров урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.

СОВЕТ КОМЫРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1610000733